ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а нче йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2022 елның 25 августы** **Олы Әшнәк авылы** **№ 17**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 14 декабрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында»гы 17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук Җир һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында" 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Әшнәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 14 декабрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына аукцион үткәрү тәртибенең 4 пунктына үзгәрешләр кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Аукционда оештыру-хокукый формасына, милек рәвешенә, урнашу

урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы юридик зат, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына (алга таба – урнаштыру өчен шартнамә) шартнамә төзүгә дәгъва итүче шәхси эшмәкәр яки һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) катнаша ала.».

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Хөснетдинова